**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссияләр турында» 2001 елның 28 декабрендәге 1500 номерлы Указы нигезендә, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамаларының үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия турында» 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-66 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 19 июлендәге ПУ-479 номерлы, 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-474 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-586 номерлы, 2011 елның 2 апрелендәге ПУ-181 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-626 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы һәм 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1234 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.В. Вайданы, Ф.Р. Волкованы чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Вәлиев Револь Миргалим улын – юридик фәннәр докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының халыкара һәм Европа хокукы кафедрасы профессоры, Россия Федерациясенең атказанган юристы, Татарстан Республикасының атказанган юристын (килешү буенча);

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын – Татарстан Республикасы юстиция министрын;

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Р. Гайзатуллинның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Л.Ю. Глухованың – «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы», аны Комиссия рәисенең урынбасары итеп расларга;

Т.В. Забегинаның – «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Эбиволь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча)»;

И.Г. Тархановның – «Казан (Идел буе) федераль университетының юридик факультеты фәнни җитәкчесе, Казан (Идел буе) федераль университетының җинаятькә каршы көрәшү хокукы кафедрасы профессоры, Комиссия рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ ПУ-637